**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 20 июле №1146

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын эшләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы 24 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барый авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү максатларында, Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын эшләүгә керешергә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасарына:

- күрсәтелгән техник (шәһәр төзелеше) йөкләмәгә ярашлы рәвештә Генераль планны эшләү өчен башлангыч мәгълүматларны әзерләүне тәэмин итәргә;

- җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик кызыксынучы затлар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә;

- Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24, 25 статьялары таләпләре нигезендә проектны карауны, килештерүне, раслауны башкарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы

муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (инфраструктур үсеш, төзекләндерү һәм ТКХ буенча) Р.Р. Баржановка йөкләргә.

. Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р.Баржанов